**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740,село Актаныш,пр.Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, 3-44-14

КАРАР ________

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте комиссиясе турында» 2010 елның 09 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указын, «Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 09 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-897 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне кушымта (1 нче кушымта) нигезендә яңа редакциядә расларга.
2. Актаныш муниципаль районы Башлыгының «Актаныш муниципаль районы хокук бозуларны профилактикалау ведомствоара комиссиясе турында» 2007 елның 27 августындагы ПГ-22 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасының хокукый порталында һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Э.Н.Фәттахов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
_____________ ел № ____ 1
нче кушымта

**Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) киңәшү органы булып тора һәм дәүләт органнарының, муниципаль учреждениеләрнең, оешмаларның һәм предприятиеләрнең, хокук саклау органнарының һәм иҗтимагый берләшмәләрнең хокук бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән социаль, хокукый һәм башка практик чараларны гамәлгә ашыру буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, аларны кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү максатыннан оештырылды.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституция законнары, федераль законнар, Актаныш муниципаль районы Уставы, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

1.3. Комиссиянең тулы исеме - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау ведомствоара комиссиясе.

1.4. Комиссиянең кыскартылган исеме - МКПП (хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия)

1.5. Комиссия үз эшен Актаныш муниципаль районының закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, хокук саклау структуралары, шулай ук ведомство карамагына һәм оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә учреждениеләр, предприятиеләр, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр белән берлектә оештыра.

1.6. Комиссиянең максаты - Актаныш муниципаль районы территориясендә җәмәгать куркынычсызлыгын һәм хокук тәртибен тәэмин итү, гражданнарның конституцион хокукларын һәм ирекләрен яклау, җирле үзидарә органнарының нормаль эшләве өчен шартлар тудыру.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча дәүләт органнары, иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек итү.

2.2. Актаныш муниципаль районы территориясендә хокук бозу дәрәҗәсен киметү өчен шартлар тудыру һәм тәкъдимнәр эшләү, шул исәптән алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны профилактикалау һәм Актаныш муниципаль районында халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар.

2.3. Хокук бозуларны социаль профилактикалау системасын торгызу, беренче чиратта, эчүчелек, алкоголизм, тәмәке тарту, наркомания белән көрәшү; җинаятьчелек, караучысызлык, балигъ булмаганнарның сукбайлыгы; законсыз миграция; иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү.
2.4. Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе, башка киңәшү органнары белән хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү.
2.5. Актанышта хокук бозуларны профилактикалау субъектларының эшчәнлеген координацияләү.
2.6. Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә төп эш юнәлешләрен, формаларын һәм ысулларын эшләү, җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтүгә һәм Актаныш муниципаль районында законлылыкны тәэмин итүгә ярдәм итә торган чараларны координацияләү.
2.7. Актаныш муниципаль районында законлылык һәм хокук тәртибе торышын иҗтимагый мониторинглау һәм оештыру, тиешле максатчан программаларны гамәлгә ашыру барышы һәм нәтиҗәләре.
2.8. Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән гражданнар инициативаларына ярдәм итү.
2.9. Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча прокуратура, эчке эшләр органнары һәм башка хокук саклау, күзәтчелек һәм административ органнар белән хезмәттәшлек итү.
2.10. Хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча гражданнарның, иҗтимагый оешмаларның тәкъдимнәрен һәм шикаятьләрен карау.
2.11. Алкоголь продукциясе, сыра, тәмәке куллануга каршы профилактика һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру эшен координацияләү.
2.12. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү эшен оештыру.
2.13. Ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү кирәклеге турында профилактика субъектлары билгеләнгән тәртиптә хәбәр итә.
2.14. Комиссия карарларының үтәлешен тикшереп тора.
2.15. Хокук бозуларны профилактикалау программаларын һәм планнарын гамәлгә ашыруны тикшереп тора.
2.16. Җинаятьчел күренешләрнең торышы һәм тенденцияләре, аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча превентив эш нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат җыя һәм анализлый.

**3. Комиссия вәкаләтләре:**

3.1. Комиссия кабул иткән карарлар рекомендация характерында.
3.2. Муниципаль учреждениеләрнең, предприятиеләрнең һәм оешмаларның хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләргә, аларның хокук саклау органнары, җәмәгать оешмалары һәм гражданнар белән Актаныш муниципаль районында җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү, хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә максатчан программаларны һәм башка норматив хокукый актларны гамәлгә ашыру, шул исәптән алкоголь продукциясен, сыра, тәмәке куллануны чамадан тыш куллану

һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру мәсьәләләрендә үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәргә.

3.3. Тәкъдим ителә торган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә.

3.4. Үз утырышларына предприятие, учреждение һәм оешма вәкилләрен чакырырга, хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча мәгълүматны тыңларга.

3.5. Билгеләнгән тәртиптә белгечләр җәлеп итеп, тирәнтен эшләүне таләп итүче комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча эшче төркемнәр төзергә.

3.6. Хокук бозуларны профилактикалау торышына комплекслы анализ ясарга, шулай ук алкоголь продукциясен, сыра, тәмәке кулланугa каршы профилактик чаралар һәм Актаныш муниципаль районы территориясендә халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча алга таба профилактика субъектларына тәкъдимнәр әзерләргә.

3.7. Үз утырышларында Актаныш муниципаль районы башкарма хакимияте органнары һәм башка субъектларның хокук бозуларны кисәтү, аларны кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү мәсьәләләре буенча җаваплы затларын тыңларга.

3.8. Актаныш муниципаль районы башкарма хакимияте органнарыннан, вазыйфаи затлардан, җәмәгать оешмаларыннан һәм башка оешмалардан аның эшчәнлеге өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны соратып алырга.

3.9. Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча башкарма хакимият органнарының, ведомствоара комиссияләрнең коллегияләр, утырышлар һәм киңәшмәләр эшендә катнашырга.

3.10. Хокук бозуларны профилактикалау чараларын үткәрүгә җибәрелә торган финанс чараларын һәм матди ресурсларны бүлү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

3.11. Актаныш муниципаль районы Башлыгы кушуы буенча хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен җайга сала торган закон һәм башка норматив актлар проектлары буенча бәяләмәләр тапшырырга.

3.12. Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы тематик социаль әһәмияткә ия рекламаны һәм мәгълүматны хәл итү инициаторы булып чыгыш ясарга.

3.13. Профилактика субъектлары җитәкчеләренә үз карамагындагы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр бирергә.

## 4. Комиссия эшчәнлеге тәртибе

4.1. Комиссия рәис, рәис урынбасарлары, җаваплы секретарь һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

4.2. Комиссиянең персональ составы һәм аның турында нигезләмә Актаныш муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана. Комиссия еллык эш планы нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

4.3. Комиссия рәисе: комиссия эшен аның бурычларына туры китереп оештыра; еллык эш (утырышлар) планын раслый; комиссия утырышы урынын, вакытын һәм көн тәртибен билгели.

4.4. Комиссия рәисе булмаганда һәм аның йөкләмәсе буенча комиссия утырышларын уздыра.

4.5. Комиссия секретаре: комиссия утырышларына материаллар, шулай ук аның карарлары проектларын әзерләүне оештыра; комиссиянең чираттагы утырышы урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында комиссия әгъзаларына мәгълүмат бирә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә.
4.6. Комиссия утырышларга кирәк саен җыела, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр җыела.
4.7. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия карарлары утырышта катнашучы әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.
4.8. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм рәис яисә аның урынбасары һәм җаваплы секретарь тарафыннан имзалана.
4.9. Комиссия рәисе, ә ул булмаганда, рәис урынбасары чираттагы утырышны күчерергә һәм өстәмә билгеләргә хокуклы.
4.10. Комиссия әгъзалары белән беррәттән, аның утырышында көн тәртибендәге аерым мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашу өчен чакырылган затлар да катнаша ала.
4.11. Комиссия кирәк булганда күчмә утырышлар үткәрә ала.